# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Байтуган торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**17 ноябрь 2021** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Байтуган торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2021 елның 17 ноябрендә 15:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Байтуган торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм ирektән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Янгын машинасын карап тоту, янгын автомашинасы йөртүчесенә хезмәт килешүе буенча түләү;
2. Үлән чабу (хезмәт шартнамәсе буенча түләү);
3. Халыкны су белән тәэмин итү (су системасы өзеклекләрен бетерү, Байтуган авылындагы экскаваторны арендага алу шартнамәсе буенча түләү)
4. Бөек Ватан сугышы елларында катнашучы якташлар хөрмәтенә куелган һәйкәлне агымдагы ремонтлау (төзү материаллары сатып алу һәм килешү буенча түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 92 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 48 кеше, бу 52 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 48 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Байтуган торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Байтуган торак пунктында, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм irектән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Янгын машинасын карап тоту, янгын автомашинасы йөртүчесенә хезмәт килешүе буенча түләү;

2. Үлән чабу (хезмәт шартнамәсе буенча түләү);

3. Халыкны су белән тәэмин итү (су системасы өзеклекләрен бетерү, Байтуган авылындагы экскаваторны арендага алу шартнамәсе буенча түләү)

4. Бөек Ватан сугышы елларында катнашучы якташлар хөрмәтенә куелган һәйкәлне агымдагы ремонтлау (төзү материаллары сатып алу һәм килешү буенча түләү).

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы — Ю.Н. ВАСИЛЬЕВ

Совет Кулэгэшского сельского поселения
Күләгәш авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002639
АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ